КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 24 июль г.Казань № 621

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татар-стан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы; 2015 ел, 28 август, 626 нчы; 2015 ел, 25 сентябрь, 710 нчы; 2015 ел, 29 декабрь, 1000 нче; 2016 ел, 24 март, 160 нчы; 2016 ел, 13 август, 554 нче; 2016 ел, 6 декабрь, 898 нче; 2017 ел, 13 март, 134 нче; 2017 ел, 13 июль, 479 нчы; 2017 ел, 8 сентябрь, 640 нчы; 2017 ел, 7 декабрь, 943 нче; 2018 ел, 24 гыйнвар, 35 нче; 2018 ел, 26 февраль, 107 нче; 2018 ел, 12 апрель, 235 нче; 2018 ел, 3 июль, 540 нчы; 2018 ел, 13 сентябрь, 775 нче; 2018 ел, 23 ноябрь, 1042 нче; 2019 ел, 26 гыйнвар, 43 нче; 2019 ел, 4 февраль, 66 нчы; 2019 ел, 28 февраль, 141 нче; 2019 ел, 30 апрель, 366 нчы; 2019 ел, 11 сентябрь, 816 нчы; 2019 ел, 10 декабрь, 1132 нче; 2020 ел, 7 февраль, 80 нче; 2020 ел, 25 май, 421 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 –

2025 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="16">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләмнәре</td><td colspan="3">Программаны финанслауның гомуми күләме – 20 949 403,68 мең сум* тәшкил итә, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 11 905 348,8 мең сум*, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 9 044 054,88 мең сум*:<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>957 036,6</td><td>668 907,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>771 639,0</td><td>631 712,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>742 042,5</td><td>683 366,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>609 879,1</td><td>721 262,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>575 168,1</td><td>755 325,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 124 229,6</td><td>766 880,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>2 569 960,4</td><td>789 266,1</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 008 597,1</td><td>794 878,9</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 028 769,5</td><td>809 122,4</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>839 342,3*</td><td>807 777,6*</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>839 342,3*</td><td>807 777,6*</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>839 342,3*</td><td>807 777,6*</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td>11 905 348,8*</td><td>9 044 054,88*</td></tr>
<tr><td colspan="3">*2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;</td></tr>
</table>

Программаның III бүлегендә:

икенче – дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме 20 949 403,68 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

федераль бюджет акчасы исәбеннән – 11 905 348,8 мең сум;

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 9 044 054,88 мең сум.»;

Программа теркәлгән 1 нче кушымтаның «Ел ахырына хезмәт базарындагы киеренкелек коэффициенты, кеше/вакансия» юлындагы 12 графасында «0,5» саннарын «1,65» саннарына алыштырырга;

Программа теркәлгән 2 нче кушымтаның 9 графасында:

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь

инвалидларны озатып йөрү» юлында «1 779 863,1», «767 191,1», «1 012 672,0» саннарын шул ук эзлеклелектә «3 344 596,5», «774 636,1», «2 569 960,4» саннарына алыштырырга;

«Программа буенча барлыгы, шул исәптән:» юлында «1 794 493,1» саннарын «3 359 226,5» саннарына алыштырырга;

«Татарстан Республикасы бюджеты» юлында «781 821,1» саннарын «789 266,1» саннарына алыштырырга;

«федераль бюджет (җәлеп итәргә планлаштырыла торган акча)» юлында «1 012 672,0» саннарын «2 569 960,4» саннарына алыштырырга;

«Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларны озатып йөрү» ярдәмче программасында (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа):

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа паспортында:

«Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа бурычлары» юлына түбәндәге эчтәлекле 9 нчы пунктны өстәргә:

«9. Хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру»;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

<table>
<tr><td rowspan="11">«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны финанслау күләмнәре</td><td colspan="4">Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме 20 773 108,68 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 11 905 348,8 мең сум; Татарстан Республикасы бюджеты акчасы – 8 867 759,88 мең сум, шулардан 308,7 млн.сумы – инвалидларның (яшь инвалидларны кертеп) эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтүгә һәм эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтүдә озатып йөрүне оештыруга:<br>(мең сум)</td></tr>
<tr><td>Ел</td><td>Гомуми акча күләме</td><td>Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы</td><td>Татарстан Республикасы бюджеты акчасы</td></tr>
<tr><td>2014</td><td>1 611 314,39</td><td>957 036,6</td><td>654 277,79</td></tr>
<tr><td>2015</td><td>1 388 721,01</td><td>771 639,0</td><td>617 082,01</td></tr>
<tr><td>2016</td><td>1 410 779,48</td><td>742 042,5</td><td>668 736,98</td></tr>
<tr><td>2017</td><td>1 315 776,8</td><td>609 879,1</td><td>705 897,7</td></tr>
<tr><td>2018</td><td>1 315 863,1</td><td>575 168,1</td><td>740 695,0</td></tr>
<tr><td>2019</td><td>1 876 479,8</td><td>1 124 229,6</td><td>752 250,2</td></tr>
<tr><td>2020</td><td>3 344 596,5</td><td>2 569 960,4</td><td>774 636,1</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>1 788 846,0</td><td>1 008 597,1</td><td>780 248,9</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>1 823 261,9</td><td>1 028 769,5</td><td>794 492,4</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2023 | 1 632 489,9* | 839 342,3* | 793 147,6* |
| | 2024 | 1 632 489,9* | 839 342,3* | 793 147,6* |
| | 2025 | 1 632 489,9* | 839 342,3* | 793 147,6* |
| | Бар-лыгы | 20 773 108,68* | 11 905 348,8* | 8 867 759,88* |
| | *2023 – 2025 елларга акча күләме фараз характерында була, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; | | | |

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаның I бүлегенә түбәндәге эчтәлекле бүлекчә өстәргә:

«Хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән
өстәмә чараларны тормышка ашыру.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яңа коронавирус йогышлы авыруы таралуны булдырмау чаралары турында» 2020 ел, 19 март, 208 нче карары нигезендә республикада халыкның санитар-эпидемиологик иминлеген тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар комплексы гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы Хөкүмәте, җирле үзидарә органнары белән берлектә, федераль башкарма хакимият органнары белән тыгыз хезмәттәшлек итеп, коронавирус йогышлы авыруы таралуга каршы тору һәм аның республика социаль-икътисадый тормышына йогынтысын минимальләштерү чараларын тормышка ашыра.

Икътисадның риск зонасына элеккән тармакларына ярдәм күрсәтү эше алып барыла. Бу, беренче чиратта, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус йогышлы авыруы таралу аркасында вәзгыятьнең начараюы шартларында аеруча дәрәҗәдә зыян күргән Россия икътисады тармакларының исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары нигезендә оешмаларга, шулай ук, үз-үзеңне изоляцияләү режимы кертелүгә бәйле рәвештә, эшләвен чикләгән, икътисадның реаль секторында эшчәнлек алып барган оешмаларга адреслы ярдәм күрсәтелә.

2020 елның 8 июле хәленә карата тулы булмаган эш белән тәэмин итү күләмнәре республика буенча 32,8 мең кеше тәшкил итте, шуларның 24 проценттан артыгы – эшкәртү җитештерүендәге хезмәткәрләр. 2020 елның июлендә – сентябрендә эштән азат ителүгә каралган хезмәткәрләр саны 3,1 мең кеше тәшкил итте, аларның 440ы – чикләү чаралары кертелүгә бәйле рәвештә.

Хезмәт базарындагы киеренкелекне киметү буенча өстәмә чараларны оештыру максатларында Татарстан Республикасында тулы булмаган эш белән тәэмин итү режимында эшләүче предприятиеләрдән сораштыру үткәрелде.

Эш бирүчеләр тарафыннан Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләренә бирелгән мәгълүматларга караганда,

республиканың 146 предприятиесе иҗтимагый һәм вакытлыча эшләрне оештыру буенча өстәмә чараларда катнашырга теләк белдерде.

2020 елда түбәндәге өстәмә чараларны гамәлгә ашыру планлаштырыла:

эш бирүчегә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда, эштән азат ителү рискы булган оешмалар хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул исәптән:

эш бирүчеләргә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул ук вакытта аларның эшсезлек буенча пособие алу хокукы саклана;

эш бирүчеләргә эштән азат ителү рискы булган оешмаларның хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау (тулы булмаган эш вакыты режимын кертү, эшләрне вакытлыча туктату, хезмәт хакын сакламыйча яллар бирү, хезмәткәрләрне азат итү чараларын үткәрү).»;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаның II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны тормышка ашыру өлкәсендә дәүләт сәясәте өстенлекләре, аның максатлары, бурычлары һәм аны тормышка ашыру вакытлары

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 597 нче Указы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 ел, 17 ноябрь, б-1662 нче боерыгы белән расланган 2020 елга кадәрге чорга Россия Федерациясен озак вакытлы социаль-икътисадый үстерү концепциясе нигезендә, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп өстенлекләре түбәндәгеләр:

оешмаларда яшь белгечләрне, алга таба аларны даими эш урынына эшкә урнаштыру максаты белән, стажировкага җибәрү тәҗрибәсен арттыру;

балигъ булмаган балалары һәм инвалид балалары булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итүне стимуллаштыру;

физик мөмкинлекләре чикләнгән затларны хезмәт эшчәнлегенә интеграцияләү өчен, аерым алганда инвалидлар өчен махсус эш урыннары булдыру, инвалидларның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтүдә озатып йөрүне оештыру юлы белән шартлар тудыру;

халыкка һөнәри юнәлеш бирү һәм психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән мәктәп укучыларына һөнәри юнәлеш бирү системасын үстерү, аларның хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр һәм белгечлекләр буенча хезмәт эшчәнлегенә карата мотивациясен арттыру;

халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә яңа мәгълүмати мөмкинлекләрдән файдалану һәм мәгълүмат ресурсларыннан һәркем файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү;

эчке хезмәт миграциясенә булышлык күрсәтү чараларын гамәлгә ашыру.

Дәүләт сәясәтенең әлеге өстенлекләреннән чыгып, Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа булдырылды, аның максатлары – халыкны эш белән (шул исәптән инвалидларны хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итү юлы белән) тәэмин итү һәм Татарстан Республикасы икътисады өчен кадрлар потенциалын үстерү.

Әлеге максатларга ирешү өчен түбәндәге бурычларны хәл итү күздә тотыла:

1. Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренең сыйфатын яхшырту һәм һәркемгә алардан файдалана алу мөмкинлеген арттыру.

2. Эш эзләүче гражданнарны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтүнең нәтиҗәлелеген күтәрү.

3. Гамәлдәге эш урыннарын саклауга һәм яңаларын булдыруга булышлык күрсәтү.

4. Эш бирүчеләрнең кадрлар белән комплектлауга булган ихтыяҗын тулысынча канәгатьләндерү.

5. Эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чараларын тормышка ашыру.

6. Инвалидларның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү. Инвалидларның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтүдә озатып йөрүне оештыру.

7. «Хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру һәм халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» илкүләм проектының «Татарстан Республикасында хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен хезмәт базарының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» төбәк проекты кысаларында чараларны тормышка ашыру.

8. «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» һәм «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартлары тудыру» төбәк проектлары кысаларында чараларны тормышка ашыру.

Беренче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

хезмәт базарындагы хәл турында, шул исәптән социаль-хезмәт мөнәсәбәтләрен норматив-хокукый җайга салу, һөнәри квалификация яктылыгында эшче көчкә сорау һәм тәкъдим, һөнәри квалификация, әзерлек, яңадан әзерләү дәрәҗәсен исәпкә алып, хезмәт күрсәтүләрнең таләп ителүе турында, шулай ук җитештерү, эшче көчне территория һәм тармак арасында яңадан бүлү һәм чит ил хезмәткәрләрен файдалану процессына гражданнарны җәлеп итү турында мәгълүмат бирү; халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнары һәм учреждениеләре тарафыннан тормышка ашырыла торган чараларны массакүләм мәгълүмат чаралары аша («Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, радио- һәм телевизион тапшыруларны, матбугат басмаларын кертеп) мәгълүмати тәэмин итү;

халыкны эш белән тәэмин итү, хезмәт мөнәсәбәтләре мәсьәләләре буенча мәгълүмат-белешмә материалларын, норматив документлар җыентыкларын әзерләү һәм бастырып чыгару (тиражлау);

предприятие (оешма) хезмәткәрләре санын яки штатын кыскарту яисә пред-

приятиене (оешманы) бетерү планлаштырыла торган предприятиеләрдә (оешмаларда) махсуслаштырылган консультация бирү пунктларын оештыру;

халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең мобиль офисларыннан файдаланып, халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә, дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның һәм аларның гаилә әгъзаларының, хәзерге заман шартларындагы хәрби хезмәт ветераннарының социаль-икътисадый һәм хокукый хәлен, матди хәле һәм хокукый якланганлыгы дәрәҗәсен тикшерүне оештыру;

республиканың хезмәт базары торышын алга китеп фаразлау максаты белән республиканың хезмәт ресурслары базарын тикшерү һәм анализлау һ.б.

Икенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

түләүле җәмәгать эшләрен үткәрүне, матди ярдәм күрсәтеп, эш эзләүдә авырлыклар кичерүче эшсез гражданнарны, урта һөнәри белемле һәм беренче тапкыр эш эзләүче 18 яшьтән 20 яшькә кадәрге эшсез гражданнарны, гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны, 14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыруны оештыру.

Өченче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

эшсез гражданнарның үзмәшгульлегенә (оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтүне, эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвенә алганда гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәвенә алу өчен документлар әзерләүгә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) булышлык күрсәтү;

эш бирүчегә һөнәри белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар арасыннан халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре юлламасы буенча вакытлыча эшкә урнаштырылган эшсез гражданнарның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау һәм эш бирүчегә иректән мәхрүм итү рәвешендә җәза үтәтү учреждениеләреннән азат ителгән һәм эшкә (шул исәптән резервлана торган эш урыннарына) урнашкан затларның хезмәте өчен түләү чыгымнарының бер өлешен каплау.

Дүртенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

түбәндәгеләрне алдан һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шул исәптән:

инвестиция проектлары нигезендә эшчәнлекне реструктурлаштыру һәм модернизацияләүне гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләрен;

өч яшькә кадәр бала тәрбияләү буенча ялда булган, хезмәт эшчәнлегенә кире кайтырга планлаштыра торган хатын-кызларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру;

яшьләр һәм студентларның хезмәт отрядларында катнашучыларны эшчеләр һөнәрләре буенча һөнәри әзерләү;

Татарстан Республикасында яшәүче пенсионерлар, пенсия алды яшендәге һәм өлкән яшьтәге затлар арасыннан гражданнарга компьютер грамотасы нигезләрен

укыту буенча «Интернет-озын гомерлелек» проектын тормышка ашыру;

көндәшлек сәләтен арттыру, алга таба эшкә урнаштыру, үзмәшгульлек һәм эшмәкәрлек максатларында, эшсез гражданнарны, шул исәптән пенсия алды яшендәге эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру, шулай ук яраклы эш эзләү максатлары белән теркәлгән гражданнарны, шул исәптән Россия Федерациясе законнары нигезендә картлык буенча иминият пенсиясе билгеләнгән һәм хезмәт эшчәнлеген яңадан башлап җибәрергә омтылган башка категорияләрдәге пенсионерларны һөнәри укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү;

эшчәнлек (һөнәр) тармагын сайлап алу, эшкә урнаштыру, һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү максатларында, гражданнарга, шул исәптән белем бирү оешмалары укучыларына һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

эшсез гражданнарга хезмәт базарында социаль яраклашу буенча дәүләт хезмәте һәм психологик ярдәм күрсәтү, социаль яраклашу һәм эшкә урнашканда озатып йөрү буенча комплекслы хезмәт күрсәтү.

Бишенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

эшсезлек буенча пособиеләрне үз вакытында түләү һәм матди ярдәм күрсәтү юлы белән эшсез гражданнарга социаль ярдәм күрсәтүне тәэмин итү;

эшсез дип билгеләнгән тәртиптә танылган гражданнарга түләүләрне гамәлгә ашыру (халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарының юлламасы буенча һөнәри укыган һәм өстәмә белем алган чорда стипендия һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары юлламасы буенча һөнәри укыган һәм өстәмә белем алган чорда матди ярдәм түләү өлешендә);

Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегенә – дәүләт учреждениесенә эшсез гражданнар арасындагы затларга вакытыннан алда рәсмиләштерелгән пенсияләр түләү чыгымнарын каплау.

Алтынчы бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

эш бирүчеләргә квота кысаларында инвалидларны эшкә урнаштыру өчен махсус эш урыннары булдыру чыгымнарының бер өлешен каплау;

инвалидларның иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан оештырылган оешмаларда инвалидларның эш урыннарын саклап калуга бәйле булган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү;

эшләмәүче инвалидларны эшкә, шул исәптән алар өчен оештырылган (җиһазландырылган) эш урыннарына урнаштыруда булышлык күрсәтүне оештыру;

эшсез инвалидларның үзмәшгульлегенә (оештыру-консультация хезмәтләре күрсәтүне, эшмәкәрлек эшчәнлеген дәүләт теркәвенә алганда гражданнарга бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне, шулай ук тиешле дәүләт теркәве өчен документлар әзерләүдә бер тапкыр финанс ярдәме күрсәтүне кертеп) булышлык күрсәтү;

эшләмәүче инвалидларны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне, һөнәри юнәлеш бирүне, хезмәт базарында социаль яраклашуны һәм психологик ярдәм күрсәтүне һ.б. оештыру.

Җиденче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

2018 елда оешмаларның эштән азат итү куркынычы астында булган яки эштән азат ителгән, хезмәткәрләр санын яки штатын кыскартуга яки бетерүгә бәйле рәвештә башка оешмалардан алынган хезмәткәрләрне алдан һөнәри укыту һәм һөнәри яңадан әзерләү (шул исәптән Татарстан Республикасыннан читтә), шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программасын тормышка ашыруга бәйле рәвештә, эш белән тәэмин итү нәтиҗәлелеген күтәрү чараларында катнашучы хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү;

2019 елда «Хезмәт җитештерүчәнлеге һәм халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» илкүләм проектының «Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү өчен хезмәт базарының нәтиҗәлелеген күтәрү һәм халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» федераль проекты кысаларында халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында предприятиеләр хезмәткәрләрен яңадан укыту, аларның квалификациясен күтәрү чараларын тормышка ашыру;

эш бирүчеләргә эштән азат итү куркынычы астында булган, шулай ук хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү программасын тормышка ашыруга бәйле бәйле рәвештә эштән азат ителгәннән соң башка оешмалардан алынган һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше нәтиҗәлелеген күтәрү чараларында катнашучы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын өлешчә каплау.

Сигезенче бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге төп чаралар карала:

«Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм аларның тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 50 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын тудыру» федераль проекты кысаларында өч яшькә кадәрге баланы карау ялында булган хатын-кызларны, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм эш эзләү максатларында халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны һөнәри укытуны оештыру һәм мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган эшсез хатын-кызларның һөнәри белем укытуга һәм өстәмә һөнәри белем алуга, шулай ук балаларны караштырып торуны оештыруга ихтыяҗлары мониторингын үткәрү;

һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча тиешле программаны сайлап алу максатларында, һөнәрләр (күнекмәләр, компетенцияләр) буенча пенсия алды яшендәге гражданнарга һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

пенсия алды яшендәге гражданнарның чираттагы ел өчен һөнәри укытуга һәм өстәмә һөнәри белем бирүгә ихтыяҗын билгеләү максаты белән Татарстан Республикасында социологик сораштырулар үткәрү.

Тугызынчы бурычны тормышка ашыру кысаларында түбәндәге чаралар карала:

эш бирүчегә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда, эштән азат ителү рискы булган оешмалар хезмәткәрләрен ва-

кытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул исәптән:

эш бирүчеләргә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул ук вакытта аларның эшсезлек буенча пособие алу хокукы саклана;

эш бирүчеләргә эштән азат ителү рискы булган оешмаларның хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау (тулы булмаган эш вакыты режимын кертү, эшләрне вакытлыча туктату, хезмәт хакын сакламыйчаяллар бирү, хезмәткәрләрне азат итү чараларын үткәрү).

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны тормышка ашыру йомгаклары буенча 2025 ел ахырына түбәндәге нәтиҗәләргә ирешү көтелә:

теркәлгән эшсезлек дәрәҗәсе 0,6 проценттан артып китүне булдырмау;

халыкның эш белән тәэмин ителү дәрәҗәсен кимендә 61,5 процент тәэмин итү;

эшсезлекнең уртача дәвамлылыгын 2025 ел ахырына 4,5 айга кадәр киметү;

эшсез булып теркәлгән гражданнар саныннан кимендә 12 процентының һөнәри дәрәҗәсен күтәрүне тәэмин итү;

халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына эш эзләү максаты белән мөрәҗәгать иткән гражданнар саныннан кимендә 60 процентына һөнәри юнәлеш бирүне оештыру;

эшсез булып теркәлгән гражданнарның уртача еллык санының кимендә

70 процентын иҗтимагый һәм вакытлыча эшләрдә эшләвен тәэмин итү;

республикада яшәүче 14 яшьтән 18 яшькәчә балигъ булмаган гражданнар саныннан әлеге яшьтәге гражданнарның кимендә 15 процентын укудан тыш вакытта эш белән тәэмин итүне гамәлгә ашыру;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа гамәлдә булган чорда эшләмәүче инвалидлар, күпбалалы ата-аналар һәм инвалид балалар тәрбияләүче ата-аналар өчен махсуслаштырылган 1,2 мең эш урыны булдыру;

эшсез гражданнарга эшкә урнашу өчен башка урынга күчкәндә, эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченгәндә булышлык күрсәтү – эшсез булып теркәлгән гражданнар саныннан кимендә 0,3 процент;

кече эшмәкәрлек тармагына кимендә 5 мең эшсез гражданны җәлеп итү;

Татарстан Республикасының икътисадый актив халкы санының кимендә

90 процентына хезмәт базарындагы хәл турында мәгълүмат бирү;

730 меңнән артык гражданны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү;

югары белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 55 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң өч ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 65 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алты ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алты ай һәм аннан күбрәк вакыт узганнан соң эш

тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алты ай һәм аннан күбрәк вакыт узганнан соң эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 10 процент тәэмин итү;

һөнәри уку узганнан соң өч ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 20 процент тәэмин итү;

һөнәри уку узганнан соң алты ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 31 процент тәэмин итү;

һөнәри уку узганнан соң алты ай һәм аннан күбрәк вакыттан соң эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң өч ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 35 процент тәэмин итү;

өстәмә һөнәри программаларны (квалификация күтәрү программалары һәм һөнәри яңадан әзерләү программалары) үзләштергәннән соң алты ай эчендә эш тапкан һәм эш белән тәэмин ителгән яшь инвалидлар өлешен кимендә 50 процент тәэмин итү;

югары белем алганнан соң алга таба укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлешен кимендә 0,5 процент тәэмин итү;

урта һөнәри белем алганнан соң алга таба укуын дәвам иткән яшь инвалидлар арасыннан укып бетерүчеләр өлешен кимендә 15 процент тәэмин итү;

халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм күрсәтү өлкәсендәге чаралар кысаларында укыган хезмәткәрләр арасыннан эшкә урнашкан хезмәткәрләр өлешен кимендә 90 процент тәэмин итү;

эш эзләү максаты белән мөрәҗәгать иткән пенсия алды яшендәге затлар арасында эшкә урнашу өлешен кимендә 40 процент тәэмин итү.

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары: 2014 – 2025 еллар.

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа бер этапта тормышка ашырылачак, бу каралган чараларның өзлексезлеген һәм күчемлелеген тәэмин итәчәк.

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программа максатлары, бурычлары һәм чаралары яктылыгында индикаторларның фаразлана торган мәгънәләренең тулырак тасвирламасы аңа теркәлгән 2 нче кушымтада китерелә.»;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программаның III бүлегендә:

беренче абзацта «19 208 375,28» саннарын «20 773 108,68» саннарына алыштырырга;

икенче абзацта «10 348 060,4» саннарын «11 905 348,8» саннарына алыштырырга;

өченче абзацта «8 860 314,88» саннарын «8 867 759,88» саннарына алыштырырга;

Халыкны эш белән тәэмин итү буенча ярдәмче программага теркәлгән 2 нче

кушымтаның «Халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү чараларын тормышка ашыру һәм хезмәт миграциясен җайга салу. Эшкә урнашканда яшь инвалидларны озатып йөрү» ярдәмче программасының максаты, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм 2019 – 2025 елларга ярдәмче программа чаралары буенча финанслау» таблицасында:

1.9 нчы пунктның 14 графасында «394 382,4» саннарын «402 997,9» саннарына алыштырырга;

2.2 нче пунктның 14 графасында «51 335,3» саннарын «49 988,4» саннарына алыштырырга;

2.2.4 нче пунктның 6 графасында «кимендә 15» сүзләрен «кимендә 7» сүзләренә алыштырырга;

4.1 нче пунктның 14 графасында «133 219,9» саннарын «143 437,9» саннарына алыштырырга;

5.1 нче пунктның 14 графасында «705 991,6» саннарын «2 179 394,5» саннарына алыштырырга;

5.3 нче пунктның 14 графасында «65 000,0» саннарын «64 100,0» саннарына алыштырырга;

7.1 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «7.1. Эш белән тәэмин итү хезмәтенең нәтиҗәлелеген арттыру | ТР ХХЭТ ИһСЯМ, ХСЯДУ | 2019 – 2024 еллар | модернизацияләү проектлары тормышка ашырылган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең вакансияләрен сайлап алу хезмәтләренә дәгъва итүчеләр – алардан файдаланучылар, файдаланылган хезмәтләрдән канәгать булучылар өлеше – 2024 елда 90 процент, процент | 60 | кимендә 65 | кимендә 75 | кимендә 80 | 85 | 90 | | ТР бюджеты<br><br>РФ бюджеты | 1 973,7<br><br>37 500,0 | 615,5<br><br>2 624,0 | 1 045,0<br><br>4 455,0 | 950,0<br><br>4 050,0»; | | | |
| | | | модернизацияләү проектлары тормышка ашырылган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең вакансияләрен сайлап алу хезмәтләреннән | 60 | кимендә 65 | кимендә 75 | кимендә 80 | 85 | 90 | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | файдаланучылар – эш бирүчеләр, файдаланылган хезмәтләрдән канәгать булучылар өлеше – 2024 елда 90 процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Россия Федерациясе субъектлары – федераль проектта катнашучылар саны – 2024 ел ахырына 85, шул исәптән Татарстан Республикасы, берәмлек | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | | | | | | | | | |
| | | | Татарстан Республикасында модернизацияләү проектлары тормышка ашырыла яки тормышка ашырылган халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре саны, берәмлек | 1 | 2019 – 2020 елларда – 2, шул исәптән 2020 елда – 2 | 2019 – 2021 елларда – 3, шул исәптән 2021 елда – 1 | 2019 – 2022 елларда – 4, шул исәптән 2022 елда – 1 | 2019 – 2023 елларда – 5, шул исәптән 2023 елда – 1 | 2019 – 2024 елларда – 6, шул исәптән 2024 елда – 1 | | | | | | | | | |

7.3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «7.3. «Хезмәт житештерүчәнлеге һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү» илкүләм проектының «Халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү һәм хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүне тәэмин итү | ТР ХХЭТИһСЯМ, ХСЯДУ | 2020 – 2024 еллар | халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында предприятиеләрнең яңадан укыган, квалификациясен күтәргән хезмәткәрләре саны, кеше | | 2019 – 2020 елларда – 2 017, шул исәптән 2020 елда – 310 | 2019 – 2021 елларда – 2 280, шул исәптән 2021 елда – 263 | 2019 – 2022 елларда – 2 500, шул исәптән 2022 елда – 220 | 2019 – 2023 елларда – 2 500 | 2019 – 2024 елларда – 2 500 | | ТР бюджеты | | 3 966,4 | 3 360,8 | 2 814,9 | акча бүлеп бирүгә карап | акча бүлеп бирүгә карап»; | |
| | | | | | | | | | | | РФ бюджеты | | 16 909,4 | 14 327,8 | 12 000,2 | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| өчен хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру» федераль проекты кысаларында халыкны эш белән тәэмин итүгә булышлык күрсәтү һәм хезмәт базарының нәтиҗәлелеген арттыру максатларында предприятиеләр хезмәткәрләрен яңадан укыту, аларның квалификациясен күтәрү чараларын тормышка ашыру | | | яңадан укыган яки квалификациясен күтәргән хезмәткәрләр арасыннан хезмәт эшчәнлеген алып баруны дәвам итүче хезмәткәрләр өлеше, процент | | кимендә 85 | кимендә 85 | кимендә 85 | | | | | | | | | | | |

8.1.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8.1.2. «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проектын тормышка ашыру кысаларында 50 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гражданнарны һөнәри укытуны һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру | ТР ХХЭТ ИһСЯМ, ХСЯДУ | 2020 – 2024 еллар | халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары ярдәме белән һөнәри укыган һәм өстәмә һөнәри белем алган 50 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, шулай ук пенсия алды яшендәге затлар саны, кеше | | 2019 – 2020 елларда – 2 719, шул исәптән 2020 елда – 1 368 | 2019 – 2021 елларда – 4 087, шул исәптән 2021 елда – 1 368 | 2019 – 2022 елларда – 5 455, шул исәптән 2022 елда – 1 368 | 2019 – 2023 елларда – 6 823, шул исәптән 2023 елда – 1 368 | 2019 – 2024 елларда – 8 191, шул исәптән 2024 елда – 1 368 | | РФ бюджеты<br><br>ТР бюджеты | | 70962,8<br><br>16 645,6 | 88 703,5<br><br>20 807,0 | 88 703,5<br><br>20 807,0 | акча бүлеп бирүгә карап | акча бүлеп бирүгә карап»; | |
| | | | һөнәри укыган яки өстәмә һөнәри белем алган 50 һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлар, шулай ук пенсия алды | | кимендә 85 | кимендә 85 | кимендә 85 | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | яшендәге затлар санында эш белән тәэмин ителгәннәр өлеше, процент | | | | | | | | | | | | | | |

8.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «8.4. «Демография» илкүләм проектының «Хатын-кызларны эш белән тәэмин итүдә булышлык күрсәтү – өч яшькә кадәрге балалар өчен мәктәпкәчә белем бирү шартларын тудыру» федераль проекты кысаларында өч яшькә кадәрге баланы карау ялы чорында хатын-кызларны, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны һөнәри укытуны оештыру һәм аларның квалификациясен күтәрү | ТР ХХЭТИ һСЯМ, ХСЯ ДУ | 2020 – 2024 еллар | яңадан укыган һәм квалификациясен күтәргән, өч яшькә кадәрге баланы карау ялында булган хатын-кызлар, шулай ук хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызлар саны, кеше | | 1 518 | 1 518 | 1 897 | 1 897 | 1 897 | | РФ бюджеты | | 44 633,5 | 70 453,5 | 91 538,6 | | | |
| | | | | | | | | | | | РТ бюджеты | | 10 469,6 | 16 526,2 | 21 472,1»; | | | |
| | | | яңадан укыган һәм квалификациясен күтәргән, өч яшькә кадәрге баланы карау ялында булган хатын-кызларның, шулай ук мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларның гомуми санында хезмәт эшчәнле- | | кимендә 70 | кимендә 70 | кимендә 70 | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | ген башла-ганнар өлеше, кеше, процент | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | Татарстан Республикасында яшәүче мәктәпкәчә яшьтәге балалары булган хатын-кызларны эш белән тәэмин итү дәрәҗәсе, процент | 76,9 | 77,3 | 77,7 | 78,1 | 78,5 | 78,9 | | | | | | | | | |

түбәндәге эчтәлекле «9 нчы бурычның исеме: «Хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру» бүлеген өстәргә:

| 9 нчы бурычның исеме: «Хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән өстәмә чараларны тормышка ашыру» | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9.1. Эш бирүчегә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда, эштән азат ителү рискы булган оешмалар хезмәткәрләрен вакытлыча эшкә урнаштыруны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул исәптән: | ТР ХХЭТИ hСЯМ, ХСЯ ДУ | 2020 ел | | | | | | | | | РФ бюджеты<br><br>ТР бюджеты | | 133 336,2<br><br>1 346,9». | | | | | |
| 9.1.1. Эш бирүчеләргә эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать итүче гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар өчен җәмәгать эшләрен оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау, шул ук вакытта аларның эшсезлек буенча пособие алу хокукы саклана | | | эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, җәмәгать эшләренә урнаштырылган гражданнар, шулай ук эшсез гражданнар саны, шул исәптән:<br><br>эш эзләүче һәм халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнарына мөрәҗәгать иткән, җәмәгать | | 1 447<br><br>0 | | | | | | | | | | | | | |

| | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | эшләренә урнаштырылган гражданнар саны, кеше | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | җәмәгать эшләренә урнаштырылган эшсез граждан-нар саны, кеше | | 1 447 | | | | | | | | | | | | | |
| 9.1.2. Эш бирүчеләргә эштән азат ителү рискы булган оешма-ларның хезмәт-мәткәрләрен вакыт-лыча эшкә урнашты-руны оештырганда хезмәт өчен өлешчә түләү чыгымнарын каплау (тулы булма-ган эш вакыты режи-мын кертү, эшләрне вакытлыча туктату, хезмәт хакын сакла-мыйча яллар бирү, хезмәткәрләрне азат итү чараларын үткәрү) | | | эштән азат ителү рискы булган оешма-ларның хезмәткәрләре арасыннан ва-кытлыча эшләргә урнаштырылган гражданнар саны, кеше | | 1 400 | | | | | | | | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин